
ИЗГЕ ҖАНЛЫ ӘНИЛӘР!
Чәчәк эзлэп йөрим кырлардан,
Белмим Сезне ничек зурларга...


Гүзәл холыклы әниләр!
Узәннәргә тошәр идем,урләргә менәр идем.
Табалсам бәхет голләрен,сиңа да озәр идем.

Иманлы, олы йөрәкле,
кешелекле, изге җанлы,
гүзәл холыклы, шәфкатьле,
мәрхәмәтле, игелекле, юмарт,
киң күңелле, эшчән, тырыш,
тыйнак, гади, изге күңелле,
кайгыртучан ,
тугрылыклы иптәш,
үрнәк остаз һәм зыялы

***ӘНИЛӘРГӘ***

иң матур 7 котлаунамә
(7 – иң изге сан)

Әниләр көне белән!

# Мәрхәмәтле ӘНИЛӘР!

**Әниләр көне -көз аенда булгангамы,**
**Табигатьнең бик тә мул чагы,**
**Күктә кояш та бар, җан да тыныч,**
**Бәхет өчен ни кирәк тагы?!**

**Бәхет өчен кемгә нәрсә кирәк:**
**Патша бәхете – олы тәхеттер.**
**Балаларның сөеп караулары –**
**Әни өчен олы бәхеттер.**

**Шундый бәхет ташламасын Әниләрне:**
**Гади булсын – буе җитәрлек.**
**Әниләргә карап ак көнләшү белән,**
**Күз тимәсен, диеп китәрлек.**

## Игелекле ӘНИЛӘР!

Гомерләр хәзинәсенә
Өстәлде тагын бер ел.
Моңаймагыз, еллар үтә дип,
Еллар күк елмаегыз –
Шатлык-сөенечләр белән
Матур үтсен бәйрәмегез!


Котлы булсын бәйрәмегез,
Тыныч булсын көнелегез,
Шатлык-сөенечләр белән
Тулы булсын гомерегез!

Гамьле еллар, ямьле көннәр
Телибез чын йөрәктән!
Һич кичекми чынга ашсын
Без теләгән теләкләр!

# Олы йөрәкле – ӘНИЛӘР!

Бәйрәмегез котлы булсын!
Бу көн шулай күңелледер СЕЗ булганда,
Бу дөнья шулай яктыдыр СЕЗ булганга.
Бөтен җиһан шатлангандыр СЕЗ булганга.
Тирә-якта һәрчак бәйрәм СЕЗ булганда.

Бүгенгедәй сөйкемле булыгыз!
Бүгенгедәй бәхетле булыгыз:
Җәй гөлләре үскәндә дә,
Яз яфраклар ярганда да,
Көз җилләре искәндә дә,
Җиргә карлар яуганда да!


Нурлы йөзле ӘНИЛӘР!
Сөйкемле карашыгыз кояшка тиң
Бар тормышны нурга күмәсез.
Бу дөньяның барлык хикмәтләрен
Гүя тик Сез генә беләсез.
Сәламәтлек, озын гомер язсын,
Көләч һәм дәртле булыгыз
хәзергечә!
Күнелегез Сезнең күтәренке
булсын,
Сөенеп һәм сөендереп яшәгез!

**Олы йөрәкле ӘНИЛӘР!**

**Иң кирәкле кеше Сез,**
**Ышанычлы, таянырлык**
**Зур йөрәкле кеше Сез!**

**Һәркем өчен табыш булып,**
**Яшәгез Сез озак еллар.**
**Киләчәккә теләк гади:**
**Аермасын безне юллар.**



# Хөрмәтле ӘНИЛӘР!

Озын гомер бирсен Хак Тәгалә,
Тыныч булсын һәрчак жаннарыгыз,
Кочак-кочак бетмәс куанычлар,
Төяп килсен туар таңнарыгыз.

Күпме булса жирдә изге теләк –
Без телибез сезгә барын да.
Ап-ак карлар кебек бәхет яусын
Бәйрәмегезнең һәрбер таңында.

Йөрәгегезгә жыйган яхшылыклар
Изгелекләр булып кайтсыннар.
Туар таңнар алып килсен сезгә
Сәламәтлек, бары шатлыклар!.

# Әниләр

- ***1998 елда Россия президенты Б.Н.Ельцин Указы нигезендә ноябрьнең соңгы якшәмбесе ӘНИЛӘР КӨНЕ итеп игълан ителде***



# Ана



*ек исем,*

*әрсә җитә ана*

*пуга;*

*атыннарның бөтен*

*атурлыгы.*

*өтен күрке ана*

*улуда...*

*Һади Такташ*

# *Шигъри дөнья*

- **Күгәрченнәр гөрләшәләр**
  **Язгы кояш нурында....**

***Җ.Тәрҗеманов***
***“Иң матур җыр”***

# Дәвам ит

- **И туган тел, и матур тел,…**

**Әткәм әнкәмнең теле!...**




Г.Тукай "Туган тел"

# Дәвам ит

- \- Син яраткан иң матур сүз

Нинди сүз әйт, бәбкәем?...



Н.Исәнбәт "Иң матур сүз"

# Дәвам ит

- Көннәр якты булсын өчен,

  Йокы татлы булсын өчен. ...




Р.Миңнуллин "Әни кирәк"

# *Мәкальнең башы минем тел очында, ахыры кемдә икән?*

- Әткәй шикәр, ...
- Әйнең яме....
- Яктылык кояш янында,

  ................................ .
- Ата-ананы тыңлаган - адәм булган,

  ........................................ .

Дөньяда иң йомшак нәрсә -

........................................ .

# Минем кадерлеләрем



# Минем әнием



# Әниемә булышам



# Бәйрәм белән котлыйбыз

